Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәһәр тибындагы
Совет поселогы
423060, Аксубай штп,
Советлар урамы, 2 нче йорт
т.2-73-62

Совет поселка городского типа
Аксубаево
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423060, пгт Аксубаево,
ул.Советская, д.2
т. 2-73-62

# КАРАР

**№93** **19 сентябрь 2024 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай штп Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2015 елның 16 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советының«Физик затлар мөлкәтенә салым турында " 2015 елның 16 октябрендәге 10 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 елның 10 ноябрендәге 73 номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 103 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2 пункт өстәргә:: «4.2.2025 елда-1,2 процент, 2026 елда-1,2 процент, 2027 елда - 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда-гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы биналарга карата 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгәннәр,
- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган".

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubayevo.tatar.ru һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны советның финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай шәһәр тибындагы
поселогы башлыгы урынбасары: Бакиров А.М

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА АКСУБАЕВО
ИНН 1603001334 ОГРН 1021605354086